**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ**
**КОМИТЕТ**

**ТАТАРСТАН**
**РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422750, село Большая Атня,
улица Советская, дом 38

422750, Олы Әтнә авылы,
Совет урамы,38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.10. 2023 №756

**«2024 елга «Әтнә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге балаларын йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативларын раслау турында»**

1. Түбәндәгеләрне расларга:

2024 елга гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары;

Гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турында нигезләмә.

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

гомуми белем бирү оешмаларын үз укучыларын әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативларына туры китереп финанслау.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А.Ф. Каюмов

Әтнә район башкарма комитеты
җитәкчесеӊ 2023ел 25
октябрендәге 756 номерлы
карары белән расланган.

2024 елга гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнеӊ бәя нормативлары

| Автотранспорт чарасы моделенеӊ исеме | Ике ставкалы нормативныӊ күләме | |
|---|---|---|
| | бер автотранспорт чарасына ставка, бер елга исәпләнгән сумма | автотранспорт чарасыныӊ бер километр йөрешенә ставка, бер елга исәпләнгән сумма |
| КАВЗ | 644807 | 23,31 |
| ПАЗ | 645065 | 23,47 |
| ГАЗ «Газель» | 624397 | 14,55 |
| УАЗ | 623944 | 13,18 |
| FIAT | 627292 | 10,99 |
| Peugeot Boxer | 632442 | 10,56 |
| Ford Transit | 632699 | 15,19 |
| Камаз Марко-Поло3297 | 647022 | 20,69 |

Әтнә район башкарма комитеты
җитәкчесең 2023ел 25 октябрендәге
756 номерлы карары белән расланган.

Гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турында
нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән (алга таба - муниципаль хезмәт) йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү механизмын билгели.
1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе, автотранспорт чаралары саны һәм отчет чорында автотранспорт чараларының чын йөреше нормативы нигезендә исәпләнә.
1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары ел саен Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитеты тарафыннан раслана.
1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен формалаштырганда автотранспорт чараларының чын йөгереше турында мәгълүмат Татарстан Республикасында автотранспорт чараларының аерым төрләрен мониторинглауның бердәм системасы мәгълүматлары буенча автотранспорт чарасының расланган маршрут паспорты кысаларында башкарылган хисап елында автотранспорт чарасының чынлыктагы йөреше буларак кабул ителә.

2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү

2.1. Муниципаль берәмлекнең муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$S_i = \sum_{m=1}^{k} (n_{f\,m} \times NF_{km_m} + NF_{as\,m} \times M_m)$$

$S_i$ - муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе;
$n_{f\,m}$ - m моделе автотранспорт чараларының чынлыктагы йөреше, километрлар;
$NF_{km_m}$ - гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны балаларны бер километрга йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру бәясе нормативы ставкасы, сум;
$NF_{as\,m}$ - гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән бер автотранспорт чарасына йөртүне оештыру бәясе нормативы ставкасы, сум;
$M_m$ - m моделе автотранспорт чаралары саны, берәмлекләр;
$m$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус моделе номеры;
$k$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус модельләре саны.